ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.06.2024 г. Казань № 432/2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 7 февралендәге 132 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарын һәм вазыйфаи затларын дәүләт серенә кертү кагыйдәләре нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының кушымтада бирелгән исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалуын танырга:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 19.12.2017 № 438;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 19 декабрендәге 438 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү турында» 13.11.2021 № 655/2021.

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 03.06.2024 № 432/2024 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында вазыйфаларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне файдалануга бәйле, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Эшләр идарәчесе;
2. Юридик бүлек җитәкчесе;
3. Финанс хисабы, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге җитәкчесе;
4. Мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлеге җитәкчесе;
5. Финанс хисабы, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
6. Контроль-ревизия бүлеге җитәкчесе.